Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАРЫ

27 октябрь 2022ел №46

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфа окладларының акчалата бүләкләү күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 57 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына(Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 59 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 90 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы тәртибе һәм шартлары турында»гы карарга кушымтаның 6 пункт 2 пунктчасында, 7 пункт 3 пунктчасында «(авырлыгы, киеренкелеге, хезмәттә югары казанышлары, махсус эш режимы)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәя нитәргә:

Әлмәтмуниципаль районы
Колшәрип авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт
Окладлары күләме

| «Вазыйфаисеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 11 группа |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 17937,00 |
| Авылбашкарма комитеты җитәкчесеурынбасары | 17579,00 |

1.3. 2 нче кушымтадагы таблицаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәре»

| «Вазыйфаисеме» | Вазыйфа оклады |
|---|---|
| | 11 группа |
| Башлык | 17944,00 |
| Башлык урынбасары | 12894,00 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле финанс чыгымнары белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджет такаралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» Интернет-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

4. Бу карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Колшәрип
авыл җирлеге башлыгы — А.Ф. Кәшәфетдинов